1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган беренче этап халык җыенын - узган дип, беренче этап халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип таныргa.

"Сез 2020 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: Түбән Бәрәскә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; күперне төзекләндерү, төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту; парк әйләнәсен чистартып тору очен чыгымнар тоту һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү, паркка балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру; урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту" мәсьәләсен кабул итәргә.

2.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган беренче этап халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган беренче этап халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Фатыхова А.В.

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеген Түбән Бәрәскә торак пунктында беренче этап гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“16” ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 10 ноябрендә «Сез 2020 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Түбән Бәрәскә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; күперне төзекләндерү, төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту; парк әйләнәсен чистартып тору очен чыгымнар тоту һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү, паркка балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру; урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча беренче этап халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Беренче этап халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 330 (өч йөз утыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 323 ( өч йөз егерме өч) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беренче этап халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен беренче этап халык җыенында катнашучы 323 ( өч йөз егерме өч ) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, беренче этап халык җыены карар итте: